ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 март 2021ел № 2050

Башкарма комитетның 2019 елның 29 июлендәге 3863 номерлы карары белән расланган каты коммуналь калдыкларны җыю урыны (мәйданчыгы) турындагы мәгълүматны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннары (мәйданчыклары) реестрына кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Каты коммуналь калдыкларны җыю урыны (мәйданчыгы) турындагы мәгълүматны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннары (мәйданчыклары) реестрына кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 29 июлендәге 3863 номерлы карары белән расланган каты коммуналь калдыкларны җыю урыны (мәйданчыгы) турындагы мәгълүматны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннары (мәйданчыклары) реестрына кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктның 4 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

2) 2.3 пунктта «баш тарту турында карар» сүзләрен «баш тарту турында белдерү кәгазе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү һәм аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия | 1) муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бүлмәләрдә һәм биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 12 пункты;<br>«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау |

| | | |
|---|---|---|
| Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга таләпләр | турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла.<br>2) инвалидларга тәэмин ителә:<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бинага, бүлмәгә тоткарлыксыз керү (керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып);<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар, бүлмәләр урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>- инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;<br>- ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>- закон нигезендә билгеләнә торган форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә юл күрсәтүче этне кертү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтә торган оешмаларның хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә муниципаль хезмәттән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү. | турында»<br>1995 елның<br>24 ноябрендәге<br>181-ФЗ номерлы<br>Федераль законның<br>15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән таләпләр бары тик файдалануга яңа тапшырылган яки реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга гына куела. | |

4) 3.1.2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

5) 3.4.1-3.4.4 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече гамәлгә ашыра:

1) гаризага теркәлгән документлардагы мәгълүматларны тикшерүне;

2) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булуны тикшерүне;

3) проект әзерләүне:

- әлеге регламентка 3 нче кушымтада каралган форма буенча, ККК җыю урыны (мәйданчыгы) турындагы мәгълүматларны Реестрга кертү турында карар (алга таба – карар проекты) (муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта);

- әлеге регламентка 4 нче кушымтада каралган форма буенча, ККК җыю урыны (мәйданчыгы) турындагы мәгълүматларны Реестрга кертүдән баш тарту турында белдерү кәгазе (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе проекты) (муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булган очракта);

4) карар проектын яки баш тарту турында белдерү кәгазе проектын килештерү өчен район хакимияте Башлыгы урынбасарына җибәрүне.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен хакимият Башлыгы урынбасарына җибәрелгән карар проекты яки баш тарту турында белдерү кәгазе проекты.

3.4.2. Район хакимияте Башлыгы урынбасары карар проектын яки баш тарту турында белдерү кәгазе проектын карап тикшерә, килештерә һәм килештерү өчен район хакимияте Башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар карар проекты яки баш тарту турында белдерү кәгазе проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен район хакимияте Башлыгына җибәрелгән карар проекты яки баш тарту турында белдерү кәгазе проекты.

3.4.3. Район хакимияте Башлыгы карап тикшерә:

- карар проектын, аны килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә;

- баш тарту турында белдерү кәгазе проектын, аны килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты яки баш тарту турында белдерү кәгазе проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән карар проекты яки имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрелгән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты.

3.4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе карар проектын карап тикшерә, имзалый һәм теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару

идарәсенә җибәрелгән карар проекты.»;

6) түбәндәге эчтәлектәге 3.4.4.1 пункт өстәргә:

«3.4.4.1. Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары баш тарту турында белдерү кәгазе проектын карап тикшерә, имзалый һәм теркәү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм теркәү өчен җибәрелгән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты.»;

7) 3.4.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.5. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) имзаланган карар проектын Башкарма комитет карарларын теркәү журналында теркәүне;

2) тарату реестры нигезендә Башкарма комитетның теркәлгән карары күчермәләрен бирүне.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура имзаланган карар проекты эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитетның теркәлгән һәм тарату реестры нигезендә бирелгән карары күчермәләре.»;

8) түбәндәге эчтәлектәге 3.4.5.1 пункт өстәргә:

«3.4.5.1. Белдерү кәгазен теркәү Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарының чыгу корреспонденциясе журналында гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән прцедура имзаланган белдерү кәгазе кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән белдерү кәгазе»;

9) 1.6, 1.6.1, 1.6.2, 1.6.3 пунктларны 3.6, 3.6.1, 3.6.2, 3.6.3 пунктлар дип санарга;

10) 1.7, 1.7.1, 1.7.2, 1.7.3 пунктларны 3.7, 3.7.1, 3.7.2, 3.7.3 пунктлар дип санарга;

11) регламентка 3 нче кушымтаның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Ф.И.А.и., ____________ районы хакимияте Башлыгы Ф.И.А.и. йөкләргә.»;

12) регламентка 4 нче кушымтаны кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Комсомол районы хакимияте Башлыгы А.И. Кисловка, Үзәк районы хакимияте Башлыгы И.Н. Галимовка, Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 25 мартындагы
2050 номерлы карарына
кушымта

Каты коммуналь калдыкларны җыю урыны (мәйданчыгы) турындагы мәгълүматны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннары (мәйданчыклары) реестрына кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Каты коммуналь калдыкларны җыю урыны (мәйданчыгы) турындагы мәгълүматны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннары (мәйданчыклары) реестрына кертүдән баш тарту турында белдерү кәгазе формасы

________________________________________

________________________________________

(гариза бирүченең (гариза бирүче вәкиленең) Ф.И.А.и., адресы)

________________________________________

(гариза бирүченең теркәлү номеры)

Каты коммуналь калдыкларны җыю урыны (мәйданчыгы) турындагы мәгълүматны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннары (мәйданчыклары) реестрына кертүдән баш тарту турында белдерү кәгазе

«_____» ____________ 20____ ел     № _____

__________________________________________________________________________________

(җирле үзидарә органының исеме)

__________________________________________________________________________________

(гариза бирүченең Ф.И.А.и. юнәлеш килештә, исеме, шәхесне раслый торган документның номеры һәм бирү датасы,

__________________________________________________________________________________

почта адреы – физик зат өчен; тулы исеме, ИНН,

__________________________________________________________________________________

КПП (Россия юридик заты өчен), ил, теркәлү датасы һәм номеры (чит ил юридик заты өчен),

_________________________________________________________________________________,

почта адресы – юридик затлар өчен)

__________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________ сәбәпле,

(баш тарту нигезе)

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 августындагы 1039 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләренең 25 пунктының «____» пунктчасы нигезендә,

______________________________________________________________________
(булдыру планлаштырыла торган контейнер мәйданчыгының урнашу урынына тасвирлама)

______________________________________________________________________

ККК җыю урыннарын (мәйданчыкларын) булдыруны кире кагу турында хәбәр итә.

Башкарма комитет
Җитәкчесенең
беренче урынбасары
МУ

_______________________ (имза)

_______________________ (Ф.И.А.и. – имза расшифровкасы)

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Бареева